| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Исенбаевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Исәнбай авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.10.2024 Исәнбай авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Исәнбай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2024 елның 30 октябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Исәнбай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2024 елның 30 октябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 этап: Исәнбай авылы Совет ур., Хезмәт ур., Речная ур., Ленин ур. халкы

-2 этап: Исәнбай авылы Мәктәп ур., Береговая ур., Яшьләр ур., Кирпич ур., Октябрь ур. халкы

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2025 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай авылы территориясендә яшәү

урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, студентлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган затлар, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

**1. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

1.1 энергияне саклый торган фонарьлар, лампалар һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм аларга алмаштыру, электрикка хезмәт килешүе буенча түләү..

**2. Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

2.1 сантехник материаллар сатып алу һәм җирлекне су белән тәэмин итү (тирән насослар сатып алу һәм ремонтлау, суүткәргеч челтәрен ремонтлау)

**3. Торак пункт территориясен төзекләндерү:**

3.1 Исәнбай авылында рөхсәтсез чүплекләрне бетерү өчен дизель ягулыгы, дизель мае һәм трактор запас өлешләрен тоту, хезмәт күрсәтү һәм сатып алу, чүп үләннәрен чабу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм төзекләндерү буенча башка чыгымнар.

**4. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:**

4.1 Исәнбай авылында Совет, Октябрь, Яшьләр, Кирпеч урамнары, Совет һәм Ленин урамнары арасындагы 2 тыкрык буенча вак таш сатып алу һәм юлларны өлешчә ремонтлау, Исәнбай авылы урамнарын кардан чистарту.

**5. Ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү**:

5.1 Вывескаларны ремонтлау һәм урнаштыру, традицион күмү урыннарын төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Исәнбай авылы, Совет урамы, 79 йорт, авыл мәдәният йорты.

7. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Р.Р.Мухаммадиев